**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2016 елның 20 апреленнән** **№19**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелүгә бәйле рәвештә КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр һәм өстәмәләр кабул итәргә:

1.1. 7 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;».

1.2. 32 статьяда:

1) 6 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашырга (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән күчемсез милек милекчеләре ширкәтләре һәм профсоюзлар ширкәтеннән, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советыннан, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләреннән тыш), әгәр федераль законнарда яисә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә башкасы каралмаган булса, аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса;»

2) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Җирлек Советы депутаты «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. “Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, “Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, җирлек Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

1.3. 43 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән

чикләүләрне үтәмәгән очракта, җирлек Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.»

1.4. 46 статьяда:

1) 4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашырга (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән күчемсез милек милекчеләре ширкәтләре һәм профсоюзлар ширкәтеннән, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советыннан, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләреннән тыш), әгәр федераль законнарда яисә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә башкасы каралмаган булса, аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса;»

2) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Җирлек башлыгы «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Җирлек башлыгының вәкаләтләре «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 12 сентябрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны һәм (яисә) чит ил финанс инструментларына ия булуны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

1.5. 48 статьяда:

1) 7 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашырга (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән күчемсез милек милекчеләре ширкәтләре һәм профсоюзлар ширкәтеннән, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советыннан, муниципаль берәмлекләрнең бүтән берләшмәләреннән тыш), әгәр федераль законнарда яисә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә башкасы каралмаган булса, аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса;»

2) түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8. Җирлек башлыгы урынбасары «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Җирлек башлыгы урынбасарының вәкаләтләре «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 12 сентябрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм счетлары (кертемнәре) булуны, акчалар һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

1.6. 53 статьяның 20 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итә, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;».

2. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл

җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга һәм муниципаль берәмлек территориясендә түбәндәге адреслар буенча махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балтач ав., Мәктәп ур., 1 нче йорт

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Балтач ав., Мәктәп ур., 2 нче йорт

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районының Балтач авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы ,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль
районының Балтач авыл җирлеге
Советы рәисе Д.И.Мөмәммәдуллин.

Кушымта

# «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» ГЫ КАРАР ПРОЕКТЫНА КАРАТА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ҺӘМ АНЫҢ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУЛАРДА КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы, Кама Тамагы районы, Караталга авылы, Мостовая ур., 5, факс буенча 30-4-16 номерлы язма рәвештә кушымтада бирелгән үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә:

| | Пункт | Карар проекты тексты | Автор проекты тексты | Төзәтмәләрне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф. и. о., адрес, телефон, эш урыны, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында карар игълан ителгән көннән алып бер ай эчендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: ТР, Кама Тамагы районы, Караталга авылы, Мостовая ур., 5, шәхсән яисә почта аша (“Устава турында” яисә “гавами тыңлаулар” конвертында тамга белән), шулай ук факс буенча 30-4-16.

Гаризалар гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты секретаре тарафыннан теркәлә һәм «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советына карау өчен тапшырыла.